Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Советының бишенче чакырылышының өченче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

20 ноябрь, 2025 ел № 18

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставының 92, 93, 94 статьялары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 21 маендагы 41/235 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2016 елның 5 февралендәге 31, 27 декабрендәге 77, 2017 елның 13 июле 100, 2018 елның 17 гыйнвары 126, 2018 елның 24 июле 153, 2018 елның 28 феврале 234, 2020 елның 26 октябрендәге 21, 2021 елның 29 декабрендәге 135, 2022 елның 11 августындагы 180, 2023 елның 23 ноябрендәге 279, 2024 елның 15 октябрендәге 353 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. «Вперед» район газетасының вакытлы матбугат басмасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Россия Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» хокукый порталында (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
башлыгы урынбасары А.С. Шәйхисламов

Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Советы
карарына кушымта
20 ноябрь, 2025 ел № 18

# Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

6 статьяның 1 өлешендәге 14 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спортка әзерлекнең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру,» сүзләрен өстәргә.

2. 7 статьяның 2 өлешендә «Россия Федерациясе субъектлары законнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга.

3. 21 статьяның 4 өлешендәге өченче абзацында «якындагы сессия» сүзләрен «якындагы утырыш» сүзләренә алмаштырырга.

4. 30 статьяның 2 өлешендә «беренче сессия» сүзләрен «беренче утырыш» сүзләренә алмаштырырга.

5. 31 статьяның 3 өлешендә:

а) 9 пунктта «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 12 пунктның «а» пунктчасында «Районның сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3.3-1 пунктчасында «кулланылырга мөмкин» сүзләрен «куллanыла» сүзенә алмаштырырга.

6. 38 статьяның 1 өлешендә «туктатылырга мөмкин» сүзләрен «туктатыла» сүзенә алмаштырырга

7. 40 статьяның 5 өлешендә:

а) беренче абзацта «сессияләр» сүзен «утырышлар» сүзенә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе)» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыклары (Рәис) (Татарстан Республикасы Премьер-министры)» сүзләренә алмаштырырга.

8. 42 статьяның 1 өлешендә «беренче сессия» сүзләрен «беренче утырыш» сүзләренә алмаштырырга.

9. 49 статьяда:

а) 1 өлешнең 1.6 пунктының 1 пунктчасында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спортка әзерлекнең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыра,» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлешнең алтынчы абзацында «йөкләнергә мөмкин» сүзләрен «йөкләнә» сүзенә алмаштырырга.

10. 55 статьяның 7 өлешендә «сессия» сүзен «утырыш» сүзенә алмаштырырга.

57 статьяның 4 өлешендә «булырга мөмкин» сүзләрен «билгеләнеп куела» сүзенә алмаштырырга.

12. 81 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «Россия Федерациясе субъектлары законнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга.

13. 85 статьяның 8 өлешендәге беренче абзацында «Россия Федерациясе субъектлары законнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга.

14. 90 статьяның 4 өлешендә «Россия Федерациясе субъекты» сүзләрен «Татарстан Республикасы» сүзләренә алмаштырырга.

15. 92 статьяның 4 өлешендә «сессия» сүзен «утырыш» сүзенә алмаштырырга.